ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

04.08.2026 **г.Чистополь** **№** 326

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы реклама чараларын урнаштыру хокукына ачык аукционнар үткәрү турында» 2022 елның 25 февралендәге 132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында «Акционерлык җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон (2 маддәнең 7 пункты), «Җаваплылыгы чикләнгән ширкәтләр турында» 1998 елның 08 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон (2 маддәнең 5 пункты) нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы реклама чараларын урнаштыру хокукына ачык аукционнар үткәрү турында» 2022 елның 25 февралендәге 132 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- 3 нче кушымтада (ачык аукционны әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә...) 4.5 пунктның тугызынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:
«- затның мөрәҗәгать итүче - юридик зат исеменнән гамәлләр башкару вәкаләтләрен раслый торган документ (физик затның мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамәсез эш итү хокукына ия булган вазыйфага билгеләү яисә сайлау турында карар яисә аны билгеләү турында боерык күчермәсе (алга таба-җитәкче)). Әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән башка зат эш итсә, аукционда катнашуга гаризада шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләр башкаруга җитәкче яисә әлеге җитәкче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан имзаланган ышанычнамә яисә мондый ышанычнамәнең нотариаль таныкланган күчермәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышанычнамә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, торгларда катнашуга гаризада шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслый торган документ булырга тиеш. Әгәр мөһер булу бурычы федераль законда яки җәмгыять Уставында каралмаган булса, юридик затның мөһере булу турындагы таләп кулланылмый.».
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов